**ГЛАВА
СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Урта Камышлы ав.

**КАРАР**

**«11» ноябрь 2023 ел** **№ 5**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп урамы, 5нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Комсомол урамы 1-61нче йортларда, Мәктәп урамы 1-20нче, Есенин урамы 1-17нче, Клуб урамы 1-5нче, Пушкин урамындагы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2023 елның 24 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Чияле Алан авылы, Мәктәп урамы, 5нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ленин урамы 1-53нче йортларда, Гагарин урамы 1-76нчы, Мичурин урамында 1-16нчы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Чияле Алан авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- Авыл эчендәге юлларны сезонлы карап тоту”.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина